ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 п.г.т.Алексеевское № 190

**2020 елда муниципаль ихтыяҗлар өчен
төзелгән контрактлар (шартнамәләр)
шартларын үзгәртү мөмкинлеге турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 112 маддәсендәге 65 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен төзелгән контрактларның (шартнамәләрнең) шартларын үзгәртү турында» 2020 елның 11 маендагы 921-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә

**карар кылам**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен төзелгән контрактларга (шартнамәләргә) карата яклар килешүе буенча контрактны башкару срогын һәм (яисә) контракт бәяләрен, һәм (яисә) товар берәмлегенең, эш, хезмәт күрсәтүнең («Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсендәге 24 өлешендә каралган очракта) бәяләрен үзгәртү рөхсәт ителә, әгәр ул 2019-nCoV чакырылган яңа коронавирус инфекциясе таралуга бәйле рәвештә үтәгәндә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка очракларда, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан контрактның үтәлү мөмкинлеген тәэмин итәрлек шартлар барлыкка килсә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**